«Татарстан Республикасы  Зеленодольск муниципаль районының
7 нче гомуми урта белем мәктәбе» муниципаль бюджет  гомумбелем
учреждениесе

**Сәнгатьтә янган гомер.**

Татарлардан беренче профессиональ режиссер һәм күренекле актер
Газиз  Айдарский турында

Башкарды: Басамыгин Марсель Марат улы
10 нчы сыйныф укучысы
Укытучы: Хәмидова Зөлфирә Зәки кызы

2020 нче ел

## Кереш

Газиз Айдарский, татарлардан беренче профессиональ режиссер һәм күренекле актер. Аның тууына 120 ел тулды. Татар эшлеклеләренең сәнгать өлкәсендәге иҗатлары турында сөйләгәндә, Яшел Үзән районының иң күренекле шәхесләренең берсе, үз хезмәтенә фидакярләрчә бирелгән талантлы артист Газиз Айдарский турында бүген сөйләми мөмкин түгел. Ул сәхнә эшчәнлеге белән генә канәгатьләнеп, театр тамашалары куюны гына үзенең бурычы итеп яшәмәде, ә театрны күтәрүгә хезмәт иткән барлык эшләрдә армый-талмый эшләгән, мәдәни, милли тормышта зур урын алып торган.

Без мәктәптә аның туган көнен бик зурлап билгеләп үткән идек. Өлкән яшьтә булса да кызы Әлфия, язучы, драматург Йоныс Сәфиуллин, “Ватаным Татарстан” газетасы журналисты Фәния Әхмәтҗанова, Апас районының”Туган як” музей директоры Рәмис Ногманов очрашуга килде. Әлфия әтисе Газиз Айдарский һәм әнисе Сара Садыйкова турында истәлекләр сөйләде” Минем балалык аңымда, томан эчендә генә кебек булып, әткәйнең сурәте гәүдәләнә иде. Минем сабый күңелемдә әткәемннән башка бер генә ир кешегә дә урын юк иде. Әткәемне сагына идем” диде. Безнең белән аралашты, мәктәп музеенда булды, истәлекле бүләкләр калдырды.

Сара Садыйкова һәм Газиз Айдарскийга багышлап гәҗит чыгарылды, фильмнар каралды. Семинарда шәһәрнең башка мәктәп укытучылары һәм укучылары да катнашты. Үземнең эзләнү эшемне Яшел Үзән районының шушы талантлы, татарларның беренче режиссеры һәм күренекле актеры, артисты Газиз Айдарский турында язарга булдым. Аның турында күп мәгълүматлар тупладым, иҗаты, эшчәнлеге белән таныштым. Күбрәк белгән саен, милләтебезгә армый – талмый хезмәт иткән, мәдәниятебезне, театр сәнгатен үстерүдә зур өлеш керткән бу күренекле шәхеснең эшчәнлеге миндә горурлык хисе уятты.

**Фәнни эзләнүләрнең максаты:** Газиз Айдарскийның татарлардан беренче профессиональ режиссер һәм актерлык эшчәнлеге, иҗатының үзенчәлекләре, хәзерге көндә әһәмияте.

Максатка ирешү өчен, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде**:**

-Газиз Айдарскийның тормыш юлы, өйрәнү объектын ачыклау;

- Беренче "Эшче" татар театрына нигез салуда хезмәте .

-Газиз Айдарскийның актерлык эшчәнлеге турында мәгълүматлар туплау.

## Газиз Айдарскийның тормыш юлы һәм иҗаты

Газиз Айдарский (Газиз Исхак улы Вәлитов) 1899 елда Татарстанның хәзерге Яшел Үзән районына караган Айдар авылында күп балалы ярлы гаиләдә туа. Гаиләнең матди хәле авыр булу сәбәпле, Газиз 10 яшьтә Әстерхан губернасының Красный Яр шәһәрендәге бер китап кибетендә хезмәтче малай булып эшли. Газизгә китаплар белән танышу өчен киң мөмкинлекләр ачыла. Ул буш вакытларын китаплар укуга багышлый. Аның сәләтен һәм тырышлыгын күреп, аны бу кибеттә приказчик итеп калдыралар. Газиз өчен бу еллар беренче "тормыш университетлары" була.

Күренекле сәхнә осталары - Касыйм Шамил, Зәйни Солтан бу егетнең талантын күреп, аны Казанга чакыралар. 1920 нче елда Газиз Казанга күчеп килә һәм татар драма театрына артист булып урнаша.

Туган авылына ихтирам йөзеннән, ул Айдарский псевдонимын ала. Биредә Газиз Айдарский күбрәк фаҗигале язмышлы рольләрдә уйный. Замандашлары искә алуы буенча, ул рольләрне артист буларак кына башкармаган, ә кыска гына вакытка булса да, шул образларга кереп, сәхнәдә алар тормышы белән яшәгән. Газиз Айдарский уйнаган Таһир ("Таһир-Зөһрә", Незнамов "Гаепсездән гаеплеләр"), Кассио ("Отелло"), Хлестаков ("Ревизор"), Лаэрт ("Гамлет") һ.б. тамашычаларда соклану һәм тирән кичереш - тойгылар уяталар.

Газиз Айдарскийның актерлык сәләте һәм кешелек сыйфатлары нигездә замандашлары истәлекләре һәм җылы хатирәләре аша килеп ирешә. Газиз Айдарскийны чордашлары җыйнак гәүдәле, төз буйлы, гаҗәеп чибәр, тыйнак һәм шул ук вакытта горур артист буларак хәтерлиләр. Ул уйнаган спектакльләрне тамашачылар тын да алмый карап, тормышның үзе кебек кабул итеп, тамаша беткәч тә хисләреннән арына алмый торганнар.

Казан тамашачысын үзенә каратып өлгергән артист Газиз Айдарский 1922-1926 елларда Мәскәүдә Дәүләт театр сәнгате институтының режиссерлык факультетында укый. Шул ук вакытта “Кызыл октябрь”заводы эшче яшьләре белән театр түгәрәге дә алып бара, Мәскәү татар драма театры белән җитәкчелек итә. Аның спектакльләренә Муса Җәлил, Шамил Усманов, Бакый Урманче кебек күренекле кешеләр йөриләр. Муса Җәлил белән дуслык мөнәсәбәтләре аеруча игътибарга лаек. Шагыйрь үзе классик әсәрләрне, сәхнәгә куярлык итеп, татарчага тәрҗемә итә, аның спектакльләренә бәяләмә – рецензия яза. Җәен бу театр ил буйлап гастрольләрдә йөри. Донбасс, Кузбасс,Урал, Себер, Ленинград һәм башка урыннарда булып, талантлы татар яшьләрен дә труппага тарталар. Шунда укыган вакытта татарның талантлы җырчысы Сара Садыйкова белән таныша. Ике талантлы кеше. Газиз Айдарский аңа үзенең мәхәббәтен шигырь юллары белән белдерә.

**ГазизАйдарский- Сара Садыйкова**

1924 нче елда оешкан “Эшчеләр театры “ белән гастрольләрдә йөргәндә Газиз белән Сара бер берсенең акылын –фигылен өйрәнеп бетсәләр дә, тәмам аңлашырга кыюлыклары җитми. Җәен бу театр ил буйлап гастрольләрдә йөри. Донбасс, Кузбасс,Урал, Себер, Ленинград һәм башка урыннарда булып, талантлы татар яшьләрен дә труппага тарталар. Шунда укыган вакытта татарның талантлы җырчысы Сара Садыйкова белән таныша. Ике талантлы кеше. Газиз Айдарский аңа үзенең мәхәббәтен шигырь юллары белән белдерә:

Син,тик син генә ...

Тормышыма ямь бирәсең,
Давылларда каршы торган
Тау чәчәге кебек,
Миңа карап, елмаясың, көләсең .
Синең көлүең, синең күз карашың
Бер күрүдә утларга салды.
Синең назлап әйткән татлы сүзең
Йөрәгемнең түрендә калды.
Сандугачка тиңләп, тыңлыйм да сине,
Тыңлап туймыйм синең тавышыңны
Тавышыңда нинди моңнар бардыр,
Таратасың кайгы – сагышны.

Хат алышулардан соң, Газиз Сараның әти-әнисенә аның кулын сорап, хат язып җибәрә. Кызның әти-әниләре кышкы каникуллар тирәсенә никах укытырга ризалык бирәләр. Бу хатлар алышу 1924 нче елда була. Белемгә омтылучы, эш сөючән бу егетне Сараның әти-әнисе дә,туганнары да хөрмәт итәләр. Газизнең Сарага Сараның Газизгә булган тирән мәхәббәтеннән, сәнгать дөньясында әле үз сүзен әйтәчәк, аларның уртак бәхетләре - кызлары Әлфия дөньяга килә. Бу шаян күңелле, шат, сабыр кыз әтисенең һәм әнисенең иҗатын биш бармагыдай белә. Ләкин язмыш аны әти-әнисеннән бик еш аера, чөнки сәнгатькә гомерләрен багышлаган шәхесләр күбрәк халыкка хезмәт итә. Ләкин бу шатлык белән янәшә аларны кайгы да сагалап тора. Газиз бик каты авырый башлый, аңарда туберкулез табалар.

**Казанда**

Мәскәүдә укып йөргән җирләреннән алар Казанга кайталар. Берсе - Газиз Айдарский, беренче профессиональ татар режиссеры, икенчесе - Сара Садыйкова. Ике талант кешесенең Казанга беренче опера спектаклендә катнашырга кайтуы тамашачылар өчен зур вакыйга була. 1925-1926 еллар да Казан сәхнәсендә беренче татар операсы “Сания” не куюны режиссер Газиз Айдарский оештыра. Сара Садыйкова бу операда “Сания” партиясен башкара. Операга тирә-як авыллардан, шәһәрләрдән киләләр, бер буш урын булмый. Аерым арияләрне кат-кат җырлаталар. Хәтта чит ил

матбугаты да “татар халкы опера тудырды “дип билгеләп үтә. Әлеге вакыйга уңаеннан,”Советское искусство” газетасының 1925 елгы алтынчы санында Газиз Айдарскийның “Беренче татар операсы” дигән мәкаләсе дөнья күрә. Газиз Айдарский Казан театр техникумында уку-укыту эшендә булачак актерларны хәзерләүдә дә эшли. Алар өчәүләп Башкортстанның Габдулла авылына кымыз эчеп дәваланырга, ял итәргә китәләр, шуннан туры Мәскәүгә юл тоталар. Анда Әлфияне балалар бакчасына урнаштыралар, үзләре баштанаяк эшкә чумалар. Газизнең авыруы көннән-көн куәтләнә. 1933 елда ул Ялтага санаторийга китә, аны Сара үзе барып ала. Кайткач Сара , Муса Җәлил ярдәме белән, Мәскәүнең туберкулез институты больницасына салалар. 1933 елның 30нчы октябрендә ул больницада вафат була. Яраткан тормыш иптәше белән аерылышуны бик авыр кичерә Сара. Шушы авыр хәсрәтләрне аз гына булса да онытып тору өчен, ул Ташкент якларына гастрольләргә чыгып китә.

**Хатирәләр, хатирәләр**... Иске, инде саргаеп беткән көндәлек битләре...

Язмаларның бер өлеше - гарәп имлясында, икенче өлеш - урыс телендә. Газиз Айдарский кулы белән ачык һәм матур итеп язылган бу көндәлек битләрендә тарихчылар һәм сәнгать белгечләре өчен бай мәгълүматлар тупланган. Әлеге язмаларда авторның фикер тирәнлеге, кичерешләре дә ачык чагыла һәм күңелне тетрәндереп, дулкынланулы мизгелләр кичерергә мәҗбүр итә. Бигрәк тә гомеренең соңгы айларына караган язмалары тирән кичерешле, фаҗигале. Әйе, татарлардан беренче профессиональ режиссер һәм күренекле актер Газиз Айдарскийның язмышы, фаҗигале булуы ягыннан, башка олуг шәхесләребезнең язмышына охшаш...

Газиз Айдарский белән эшләгән татар сәхнәсенең күренекле осталары бер тавыштан аның профессиональ дәрәҗәдә эшләвен аерым билгеләп үтәләр. “Татар театры тарихында якты эз калдырган сәхнә осталары Хәким Сәлимҗанов, Фатыйма Янбарисова, Габдулла Йосыпов һ.б этием Газиз Айдарский хакындагы җылы хатирәләре белән уртаклашып күп мактау

сүзләре әйттеләр, мин моның белән горурланам, әтиемне бик аз хәтерлим чөнки балачагым әнием ягыннан, әби-бабаларым янында - Казанда үтте. Әтием белән яшәгән елларны әнием Сара  Садыйкова еш искә алып: “ Авыррак булгае саен, әтиең белән бер-беребезгә ныграк сыендык”, - дип әйтә иде.” Газиз Айдарскийның театр сәнгате өлкәсендәге эшчәнлегенә дусты Муса Җәлилдән дә тулырак бәһа бирүче булмый. Артист сәхнә эшчәнлеге белән генә канәгатьләнеп яшәмәде. Ул тынгысыз җәмәгать эшлеклесе булды. Мәскәүдә татар эшче театрын оештыру, зур сәнгать отряды итеп үстерү юлында аның хезмәте биниһая зур булды. Газиз Айдарскийның иң кадерле сыйфатларыннан үз хезмәтенә фидакярләрчә бирелгәнлек, шуңа зур мәхәббәт һәм туктаусыз сәнгать өчен яну.

**Кызлары Әлфия ханым Айдарская Сара Садыйкова, Газиз Айдарскийның иҗатын мәңгеләштерүгә зур көч куя**. Алар исемендәге музейлар ачу,   тантаналы очрашулар оештыруда хезмәте ичкиткеч. Ул ел саен диярлек Мәскәүнең мәдәни үзәгендә әнисенең туган көнен бәйрәм итә. Әлфия Айдарская үзе белән Мәскәүгә дистәгә якын җырчылар, музыкантлар, сөйләүчеләр генә түгел, Казанда  мәрмәрдән махсус ясатылган, әтисенә багышланган истәлек ташы да алып килә Һәм тамаша алдыннан мәдәни үзәктә ул ташны ачу мәрәсиме дә була. Тактаның өске өлешендә Газиз Айдарскийның сыны ясалган,  аскарак  “Мәскәүдә татар театрына нигез салучы Айдарский (Вәлитов) Газиз Исхак улы. 1899-1933”дип язылган. Мемориаль  такта”Асадуллаевлар йортында “-  милли үзәкнең бер почмагында үзенә урын ала. Монда Газиз Айдарский 1924 елны беренче “Эшче” татар театры оештыра һәм 1933 нче елга кадәр төп режиссер һәм сәнгать  җитәкчесе дә була. Килгән халык, андый ташлар урам диварына куелырга тиеш бит, нигә соң бина эченә урнаштырганнар дигән сораулар да бирә. Бу чараны оештыручылар: “Урам якка куяр өчен аерым рөхсәт кирәк, аның артыннан күп йөрергә туры киләчәк, әлегә бина эчендә булса да ярый инде”, дип аңлаталар. Бу ачу тантанасына мохтарият

рәисе Рәсим Акчурин,Татарстаннан вәкаләтле вәкил Равил Ахметшин да катнашып чыгыш ясыйлар.

**Әлфия ханым истәлекләре**

Әлфия ханым: “Әтием белән әнием Мәскәүдә укыган вакытта шушы мәдәни үзәктән ерак булмаган урында, Зур татар урамында яшәделәр. Мине бу йортка бик еш алып килә иделәр. Бу йорт минем балачагымның бер истәлеге. Мин бирегә туган өемә кайткан кебек киләм. Бу йортта эшләүчеләр дә мине бик хөрмәтләп каршы алалар. Мин аларга бик рәхмәтле”, ди үзенең истәлекләрендә.

Шулай ук әтисе турында да истәлекләре белән уртаклашып Әлфия ханым: “Әти ул вакытта Мәскәү консерваториясендә һәм башка уку йортларында укыган татарларны җыйнап театр оештырган. Беренче биш елда алар беркайдан да бер тиен алмый үзләре эшләгәннәр. 1928 елда Наркомпрос аларга 5 мең сум бүлеп бирә. Ә инде 1929 елда алар Наркомпростан 12 мең акча ала алганнар. Ул елны бик уңышлы итеп Ленинградта гастрольләр дә уздырганнар. Ә инде гомумән алганда, алар үзләрен “Эшче” театры дип атап, татар телендә төрле завод-фабрика клубларында спектакльләр күрсәткәннәр”, диде. Тамашачылар арасында ул заман тарихын бик яхшы белгән Әхмәт Галимов та үз истәлекләре белән уртаклаша. Айдарский театры заманында беренче тапкыр Донбасс якларына барып андагы татар шахтерларын да татар театры белән таныштырган. Айдарскийның иң кадерле сыйфатларыннан үз хезмәтенә фидакарьләрчә бирелгәнлек, шуңа зур мәхәббәт һәм туктаусыз сәнгать өчен яну иде. Артист сәхнә эшчәнлеге белән генә канәгать яшәмәде. Ул, тынгысыз җәмәгать эшлеклесе буларак, үзенең бурычы итеп театр тамашалары куюны гына түгел, ә театрны күтәрүгә хезмәт иткән барлык эшләрдә армый-талмый эшләде. Мәскәүдә татар эшче театрын оештыру, зур сәнгать отряды итеп үстерү юлында аның хезмәте биниһая зур булды. Эш өчен янып яшәү ялкыны Г. Айдарскийда чиксез иде

Газиз Айдарскийның Яшел Үзән районы Күгәй авылында аның исемендә мемориаль музей ачылды. Күгәй авылында Газиз Айдарский исемендәге музей ачылуга авыл халкы, мәктәп укучылары горурланалар, бик теләп, Газиз Айдарский турында өйрәнәләр, аның турында күбрәк белергә омтылалар. Йоныс Сәфиуллин Газиз Айдарскийның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнә, Мәскәү, Казан архивларыннан төрле документлар белән таныша, 2011 нче елның сентябрь аенда Йоныс Сәфиуллинның "Газиз Айдарский" китабы басылып чыкты Газиз Айдарскийның 120 еллыгына Мәскәү мәдәният үзәгендә зур концерт булды.

Йомгаклау

Мәскәүнең татар мәдәни үзәгендә, Казан шәһәренең Актёрлар йортында да татарның беренче профессиональ режиссерларының берсе булган Газиз Айдарскийның тууына 120 ел тулуга багышланган чара булып узды. Яшел Үзәннең музыка мәктәбендә дә Газиз Айдарскийның юбилей кичәсе билгеләп үтелде. Сара Садыйкова җырлары белән үрелеп барган бу очрашу безнең күңелләрдә суынмас эз калдырды. Бу көйләрне тыңлап, Газиз Айдарский, Сара Садыйкова дөньясына чумдык, алар иҗатының бөеклеге тагын бер кат дәлилләнде. Рәхмәт сүзләребез чәчәк бәйләмнәре белән расланды. Рәхмәт Әлфия апагага. Эшләгән эшләре әти – әнисенә дога булып барсын

**Кулланылган әдәбият**

1.Газиз Айдарский/ Юныс Сафиуллин. - Казан: Идел-Пресс, 2011ел

2.Документаль кино. Россия "Театрга бирелгән гомер"

3."Калфаклы сандугач".Сара Садыйкова.Татарстан китап нәшрияты,2002ел

4."Память сердца", Айдарская А.Г. Татарское книжное издательство, 2002

Уйнаган спектакльләре. Мәскәүдә

- **«**Галиябану» Мирхәйдәр Фәйзи

-«Зәңгәр шәл» Кәрим Тинчурин

-«Казан сөлгесе» Кәрим Тинчурин


-«Наёмщик» Таҗи Гыйззәт
-«Аршин мал алан» Гозәер Хаҗибәков
«Оештыручы» Салих Баттал

## Казанда

-«Сания» операсы Солтан Габәши һ. б.

## Беренче татар үрнәк театрында

-*Таһир* — «Таһир-Зөһрә» Фәтхи Бурнаш
-*Незнамов* — «Гаепсездән гаеплеләр» А.Н. Островский
-*Хлестаков* — «Ревизор» Н.В. Гоголь
-*Кассио* — «Отелло» Уильям Шекспир
-*Лаэрт* — «Гамлет» Уильям Шекспир
















Газиз
Айдарский
музеендагы
экспозиция

